**КАРАР №47**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге Советы утырышы

20 июнь 2022 ел Күәм авылы

**Күәм авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 июнендәге 86 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2017 елның 5 декабрендәге 389-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» , 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 56 статьясындагы 2 өлеше (алга таба - җирле үзидарә турында Закон) нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 июнендәге 86 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә" Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы прокуратурасының 2022 елның 16 мартындагы 02-08-02/Прдп134-22-2092010 номерлы протестын карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 июнендәге 86 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктының өченче абзацында, 2-4 бүлекләрендә, 5.1, 6.1-6.4 пунктларында "җирле референдумда" сүзләрен "гражданнар җыенында"сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гатауллин